МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.08.2019 г.Казань № 635

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 10 сентяберендә 5785 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 19.08.2019
№ 635 боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 639 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 12.10.2015 № 730, 19.05.2016 № 278, 28.11.2016 № 668, 08.06.2017 № 349, 07.05.2018 № 350, 18.09.2018 № 858, 22.04.2019 № 290 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:

бала (балалар) туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта – балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);

балага опека билгеләнүе турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);

дәүләт хезмәте алучының ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителүе яисә ата-аналык хокукында чикләнүе турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);

мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән шартнамә төзегән зат турында белешмәләр, – 2015 елның 30 сентябреннән соң мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән шартнамә төзегән затлар өчен (Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгында);

мәгариф оешмасында баланы караштырган һәм тәрбияләгән өчен түләү квитанциясендә күрсәтелгән табель номеры турында белешмәләр, – 2015 елның 30 сентябреннән соң мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән шартнамә төзегән затлар өчен (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

Гариза бирүче Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте Инфоматлары аша мөрәҗәгать иткән очракта, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша өстәмә рәвештә гариза бирүченең паспортының чын булуын раслау турында белешмәләр алына (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Аталган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

Үзәк бүлеге мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы күздә тотылмаган документларны тиешенчә федераль башкарма хакимият органнарыннан, бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары органнарыннан, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан тапшыруны;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешма хезмәткәренең ялгыш яки хокукка каршы килә торган гамәлен (гамәл кылмавын) документаль раслаучы фактны (билгеләрне) ачыклаганда, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүче вәкаләтле оешма җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә.»;

3 бүлекнең 3.4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Ата-аналар түләве өлешендә компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында гарызнамәләр җибәрә:

Татарстан Республикасында 2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында, – вәкаләтле органга;

мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән шартнамә төзегән зат турында, – 2015 елның 30 сентябреннән соң мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән шартнамә төзегән затлар өчен, – Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына;

мәгариф оешмасында баланы караштырган һәм тәрбияләгән өчен түләү квитанциясендә күрсәтелгән табель номеры турында, – 2015 елның 30 сентябреннән соң мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән шартнамә төзегән затлар өчен, – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына;

балага опека билгеләнүе турында – җирле үзидарә органнарына;

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында – җирле үзидарә органнарына;

ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителү яисә ата-аналык хокукында чикләнү турында – җирле үзидарә органнарына;

гариза тапшыручының паспорты чын булуын раслау турында, – гариза Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән очракта, – Татарстан Республкиасы буенча Эчке эшләр министрлыгына;

Россия Федерациясе Пенсия фондына хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында гарызнамә.»;

3.5.1 пунктның алтынчы абзацында «мизгелдән» сүзен «көннән» сүзенә алмаштырырга;

3.5.2 пунктның икенче абзацында «мизгелдән» сүзен «көннән» сүзенә алмаштырырга;

3.6 пунктның өченче абзацында «мизгелдән» сүзен «көннән» сүзенә алмаштырырга;

3.8.1 пунктның бишенче абзацында «мизгелдән» сүзен «көннән» сүзенә алмаштырырга;

3.8.2 пунктның икенче абзацында «мизгелдән» сүзен «көннән» сүзенә алмаштырырга;

3.8.3 пунктның икенче абзацында «мизгелдән» сүзен «көннән» сүзенә алмаштырырга;

4 бүлекнең 4.2 пунктындагы беренче абзацында «(алга таба – Идарә (бүлек))» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 бүлектә 5.1 пунктның өченче абзацында «министр исеменә» сүзләрен төшереп калдырырга;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлегенә
_______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА № ____
«__» __________ 20__ ел.

Мин,______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)

| Шәхес таныклаучы документ атамасы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

түбәндәге адрес буенча яшим:
_____________________________________________________________________.
(индексын күрсәтеп мөрәҗәгать итүченең почта адресы, телефон номеры, электрон почта адресы)
түбәндәгеләргә нигезләнеп эш итәм:
_____________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте алучы мәнфәгатьләрендә эш итүен раслаучы документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)
Снилс (алучыныкы) ___________
Түбәндәгене билгеләүне сорыйм _______________________________________,

(дәүләт хезмәте алучының Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)
түбәндәге адрес буенча яшәүче:

_______________________________________________

(дәүләт хезмәте алучының почта адресы, яшәү урыны буенча теркәлү адресы)

_______________________________________________

(дәүләт хезмәте алучының шәхесен таныклаучы документ реквизитлары)

мәктәпкәчә белем бирү буенча мәгариф программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләве өлешендә компенсация;
Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| номеры | Документларның аталышы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |
| 4 | | |
| 5 | | |

Түләү алучының гаилә составы:

| номеры | Ф.И.А. (туу датасы) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт (бала туу турында таныклык) реквизитлары | Кирәклесен билгеләргә * |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| 3 | | | | |
| 4 | | | | |

* үзләренә карата дәүләт хезмәте билгеләнә торган балалар күрсәтелә

Раслыйм: гаризада күрсәтелгән балаларның (баланың) тулысынча дәүләт тәэминатында тормавы, шулай ук _______________________________ карата
(дәүләт хезмәте алучының Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)
ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителмәгән, ата-аналык хокукында чикләнмәгән.

_________ _______________________

(имза, тулы имза)

_______________________________________________________________________________

(балага опека билгеләнгәндә опека билгеләгән органның исемен һәм урнашу урынын күрсәтергә)

Билгеләнгән түләүләрне түбәндәгечә түләүне сорыйм:

әлеге счетка күчерү юлы белән _______________________________________________

(дәүләт хезмәте алучы яисә аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

почта бүлеге аша ______________________________________________________

(дәүләт хезмәте алучының яисә аның законлы вәкиленең почтадан җибәрү реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, аларны үз эченә алган документларның төп нөсхәләре өчен җаваплылык турында һәм социаль ярдәм чаралары түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштырылдым

______________________________

(гариза бирүченең имзасы)

Мәгълүматлар алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү турында (хезмәт күрсәтүне кире кагу турында), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында, риза:

әлеге адрес буенча язмача формада________________________________

әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ____________________________________

(телефон номеры)

электрон документ формасында

әлеге электрон почта адресына ____________________________________

(электрон почта адресы)

«Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша ______________________________

(гариза бирүченең имзасы)

Мөрәҗәгать итүче:

__________________________________________ _________ «__» _______ 20_ ел.

(дәүләт хезмәтен алучының яисә дәүләт хезмәтен алучының мәнфәгатьләрн билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышанычнамә нигезендә белдерүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)) (имза)

Гариза һәм документлар кабул ителде ______ 20__ ел. _________ ___________

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

____________________________________________________________________.

Өзү линиясе

Язу-белдерүнамә

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү №____________
Документлар саны ____ данә, __ биттә
Документларны кабул итте ___________ __________ _____________ ______________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Регламентка 3 нче кушымтада:
«Ф.И.А.» сүзләрен «Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;
Регламентка 5 нче кушымтада:
«(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)» сүзләрен «мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Тәрбиягә алынганнарын да исәпкә алып, 18 яшькәчә өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләргә торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүдә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 01 декабрендәге 670 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 19.05.2016 № 277, 28.11.2016 № 668, 27.02.2017 № 103, 08.06.2017 № 349, 14.09.2018 № 855, 22.04.2019 № 290 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Тәрбиягә алынганнарын да исәпкә алып, 18 яшькәчә өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләргә торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүдә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек итү каналлары аша түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алучы документлар алына:

балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында – балалар туу Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт теркәвенә алынган очракларда (вәкаләтле органнарда);

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында – гаилә кору Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт теркәвенә алынган очракларда (вәкаләтле органнарда);

гаилә таркатуны дәүләт теркәвенә алу турында – гаиләне таркату Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт теркәвенә алынган очракларда (вәкаләтле органнарда);

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында (җирле үзидарә органнарында);

ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү турында (җирле үзидарә органнарында);

дәүләт хезмәтен алучы белән бергә даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында (вәкаләтле органнарда);

ана карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торак урынга милекчелек хокукы турында (Дәүләт теркәвенә алу, кадастр һәм картография федераль хезмәтендә (алга таба – Росреестр);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында).

Гариза бирүче Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша мөрәҗәгать иткәндә өстәмә рәвештә ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша алына:

мөрәҗәгать итүченең паспорты чын булуы турында белешмәләр (Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгында).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Аталган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

Үзәк бүлеге мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы күздә тотылмаган документларны тиешенчә федераль башкарма хакимият органнарыннан, бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары органнарыннан, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешма хезмәткәренең ялгыш яки хокукка каршы килә торган гамәлен (гамәл кылмавын) документаль раслаучы фактны (билгеләрне) ачыклаганда, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүче вәкаләтле оешма җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә.»;

2 нче бүлекнең «Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт» графасында:

2.6 пунктта «Нигезләмәнең 9.2 п.; Нигезләмәнең 9.10 п.» сүзләрен «126 номерлы Нигезләмәнең 2.2.1 п.» сүзләре белән алмаштырырга;

2.14 пунктта «880 номерлы Тәртипнең 1.3 п.» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 бүлекнең 3.4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында гарызнамәләр җибәрә:

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында – вәкаләтле органнарда;

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында – вәкаләтле органнарда;

гаилә таркатуны дәүләт теркәвенә алу турында – вәкаләтле органнарда;

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында – җирле үзидарә органнарында;

ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү турында – җирле үзидарә органнарында;

дәүләт хезмәтен алучы белән бергә даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында, – вәкаләтле органнарда;

үзенә карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торак урынга милекчелек хокукы турында, – Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтендә (Росреестр);

Россия Федерациясе Пенсия фондына хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында;

мөрәҗәгать итүченең паспорты гамәлдә булуын раслау турында – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, әгәр гариза Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән булса;

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында гарызнамә.»;

4 бүлекнең 4.2 пунктындагы беренче абзацында «(алга таба – Идарә (бүлек))» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 бүлектә 5.1 пунктның өченче абзацында «министр исеменә» сүзләрен төшереп калдырырга;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алынганнарын да исәпкә алып, 18 яшькәчә өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләргә торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүдә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлегенә

_______________________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА № ___

_________ 20__ ел.

Мин,

____________________________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)

| Шәхес таныклаучы документ атамасы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

түбәндәге адрес буенча яшим:

____________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)

түбәндәгеләргә нигезләнеп эш итәм:

____________________________________________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте алучы мәнфәгатьләрендә эш итүен раслаучы документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)

СНИЛС (алучыныкы) ____________________

Түбәндәгегә_______________________________________________________________,

(дәүләт хезмәте алучының Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)

түбәндәге адрес буенча яши торган:

____________________________________________________________________________

(дәүләт хезмәте алучының почта адресы, яшәү урыны буенча теркәлү адресы)

____________________________________________________________________________

(дәүләт хезмәте алучының шәхесен таныклаучы документ реквизитлары)

18 яшькәчә өч һәм аннан күбрәк балалы гаилә буларак, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләвегез турында үтенәм.

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| | Документларның аталышы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Түләү алучының гаилә составы:

| | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (туган көне, ае, елы) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт (бала туу турында таныклык) реквизитлары | Кирәк-лесен билге-ләргә <*> |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

--------------------------------

<*> үзләренә карата дәүләт хезмәте билгеләнә торган балалар күрсәтелә

Гаризада күрсәтелгән балаларның (баланың) тулысынча дәүләт тәэминатында тормавы хакында раслыйм, шулай ук аларга (аңа) карата

___________________________________________________________________

(дәүләт хезмәте алучының Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителмәгәнмен, ата-ана хокукларында чикләнмәгәнмен

______________ ______________________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы, тулы имзасы)

______________________________________________________________________.

(балага опека билгеләнгән очракта, опека билгеләгән органның исемен һәм урнашкан урынын күрсәтергә)

Билгеләнгән түләүләрне түбәндәгечә түләүне сорыйм:

счетка күчерү юлы белән ____________________________________________

(дәүләт хезмәте алучы яисә аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

почта бүлеге аша ___________________________________________________

(дәүләт хезмәте алучының яки аның законлы вәкиленең почта бүлекчәсе реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, аларны үз эченә алган документларның дөреслеге өчен җаваплылык турында һәм социаль ярдәм чараларын түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турында нигезләмәләр белән таныштырылдым

__________________

(гариза бирүченең имзасы)

Мәгълүматлар алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү турында (хезмәт күрсәтүне кире кагу турында), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында, риза:

әлеге почта адресы буенча язма формада ________________________

әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ____________________________

(телефон номеры)

электрон документ формасында

әлеге электрон почта адресы буенча _________________________________

(электрон почта адресы)

«Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша

_________________________________________

(гариза бирүченең имзасы)

Мөрәҗәгать итүче:

______________________________________________ ________ «__» ________ 20__ ел.

(дәүләт хезмәтен алучының яисә дәүләт хезмәтен алучының мәнфәгатьләрн билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышанычнамә нигезендә белдерүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта)) (имза)

Гариза һәм документлар кабул ителде ______ 20__ ел.

_________ ____________________

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

______________________________________________________________________.

Өзү линиясе

Язу-белдерүнамә

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү №_________
Документлар саны ____ данә, __ биттә
Документларны кабул итте__________ _________ _________________ _________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алынганнарын да исәпкә алып, 18 яшькәчә өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләргә торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүдә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта (киңәш ителә торган рәвеше)

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ____ бүлеге
_____________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Социаль ярдәм чаралары билгеләү (бирү) турында
карар

№ ______ «__» __________

Алучының Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) _________________________________
_______________________________________________________________________
Адресы_________________________________________________________________
18 яшькәчә өч һәм аннан күбрәк балалы гаилә буларак, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләргә (бирергә)

Түләү срогы: __________ башлап _____________кадәр
Түләү ысулы ____________________________________________________________

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлеге мөдире
_______________________________ _____________________ ____________
муниципаль районда (шәһәр округында) (Ф.И.А.) (имза)

Мөһер урыны
«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлеге

белгече

______________________________ ______________ __________

муниципаль районында (шәһәр округында) (Ф.И.А.) (имза)

Гариза бирүчегә хәбәр ителде (кирәклесе астына сызарга):
әлеге адрес буенча язмача формада______________________________
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ______________________________
(телефон номеры)
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресына ______________________________
(электрон почта адресы)
«Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша ______________________
бүлекчә белгече _________________________ ______________
(Ф.И.А.) имза

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № __ бүлеге
______________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Социаль ярдәм чаралары билгеләүдән (бирүдән) баш тарту турында
карар

№ _____ «__» ______________

Алучының Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) ______________________________
______________________________________________________________
Алучының адресы ______________________________________________

18 яшькәчә өч һәм аннан күбрәк балалы гаилә буларак, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләүдән (бирүдән) баш тартырга

Баш тарту сәбәбе: ______________________________________________

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлеге җитәкчесе ______________________

______________________________ ______________ __________

муниципаль районда (шәһәр округында) (Ф.И.А.) (имза)

мөһер урыны

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлеге белгече

____________________________________ ________________________ ____________
муниципаль районында (шәһәр округында) (Ф.И.А.) (имза)

Гариза бирүчегә хәбәр ителде (кирәклесе астына сызарга):
әлеге адрес буенча язмача формада_______________________________________
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ____________________________________________
(телефон номеры)
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча ______________________________________
(электрон почта адресы)
«Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша

бүлек белгече _______________________ ___________________
(Ф.И.А.) имза»;

Регламентка 5 нче кушымтада:
«(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)» сүзләрен «мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга.